РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«04» сентябрь 2023 ел Олы Кайбыч ав. № 212

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгының, башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтен түләү турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарын түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче кушымтаның 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бер мәртәбә бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына түбәндәгеләр керә:

- вазыйфаи оклад;

тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмә;

- сыйныф чины өчен өстәмәләр;

- муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка өстәмәләр»;

- еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүнең 1/12 күләме.».

1.2. Карарга 5 нче кушымтада:

1.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән азат ителгәндә, муниципаль яисә дәүләт вазыйфаларын биләүнең гомуми стажы, дәүләт һәм муниципаль хезмәт

стажы тулаем алганда 10 елдан да ким булмаганда, ун мәртәбә акчалата түләү күләмендә, бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә.»;

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата түләү составына түбәндәгеләр керә:

- айлык акчалата түләү;

ай саен акчалата бүләкләү.».

1.3. 7 нче кушымтада «айлык акчалата түләү» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин